РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.03.2020 № 514-п

“Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Курсабаш авыл җирлеге адресы буенча урнашкан ял итү базасын газ белән тәэмин итү” линияле объектының план сызу проектын һәм межа салу проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьялары, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 16 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьялары нигезендә, Саба муниципаль районы территориясен тотрыклы үстерү, планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренең чикләрен билгеләү максатларында,территориянең план сызу һәм межа салу проектлары буенча халык тыңлаулары нәтиҗәләре нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. “Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Курсабаш авыл җирлеге адресы буенча урнашкан ял итү базасын газ белән тәэмин итү” линияле объектын урнаштыру өчен Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге территориясенең кушымта итеп бирелә торган план сызу проектын һәм межа салу проектын расларга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы И.Б.Таиповка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов